СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.03.2026 № 8/5

На №__________ от______________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Советының «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү хакында**

Тукай муниципаль районы Советының «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча фикер алышуда Тукай муниципаль районы халкының катнашу хокукларын саклау максатыннан, Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы нигезләмәгә таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.

1.1. Халык тыңлауларын үткәрү вакытын билгеләргә: 2026 елның 20 апрелендә 17.00 сәгатьтә, үткәрү урыны: Яр Чаллы ш., М.Җәлил пр., 46 й. (муниципаль район Советы утырышлар залы).

1.2. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар 2026 елның 17 апреленә кадәр почта аша җибәрелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46 йорт, 330 кабинет яисә телефон буенча: (8552)701183.

2. Тукай муниципаль районы Советының «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча халык тыңлауларын уздыру тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны һәм Тукай муниципаль районы Советының «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проектын 2026 елның 3 апреленнән да соңга калмыйча, «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга һәм Тукай районының рәсми сайтында

урнаштырырга.

4. Түбәндәге составта оештыру комитетын төзергә:

- Нәҗмиев Камил Рим улы – район Башлыгы,

- Сәхбиев Мансур Шакирҗан улы – бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссия рәисе, Биклән авыл җирлеге Башлыгы,

- Вәлиева Венера Александровна – бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссия әгъзасы, Бәтке авыл җирлеге Башлыгы,

- Маняпов Линар Нурислам улы – район Башкарма комитеты Җитәкчесе,

- Кузьмина Айсылу Фәрит кызы – финанс-бюджет палатасының исәп һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары.

4. Оештыру комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2026 елның 31 мартындагы 8/5 номерлы карарына 1 кушымта

**ПРОЕКТ**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап**

«2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» турында мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 2 118 446,51 мең сум, чыгымнар буенча 2 163 795,60 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

- 2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1 кушымта нигезендә;
- 2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты керемнәре буенча әлеге карарга 2 кушымта нигезендә;
- 2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 3 кушымта нигезендә;
- 2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты чыгымнарының функциональ структурасы буенча әлеге карарга 4 кушымта нигезендә;
- 2025 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программадан тыш юнәлешләре) чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 кушымта нигезендә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе К.Р. Нәҗмиев

**Карар проектына кушымталар Тукай муниципаль районының рәсми сайтында http://tukay.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырылган.**

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2026 елның 31 мартындагы 8/5 номерлы карарына 2 кушымта

**Тукай муниципаль районы Советының 2022 ел өчен бюджет үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе**

1. Җирле бюджет проекты халык тыңлауларында Россия Федерациясе Бюджет кодексында, башка федераль законнарда, уставта, «Тукай муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» нигезләмәдә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып карала.

2. Җирле бюджет проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында карар кабул итүче орган булып муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тора.

Җирле бюджет проекты буенча халык тыңлауларын үткәрүне гамәлгә ашыручы орган булып оештыру комитеты тора.

3. Җирле бюджет проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында карар аны кабул иткәннән соң, 10 көн эчендә басылып чыгарга тиеш.

4. Җирле бюджет проекты буенча халык тыңлаулары җирле бюджет (җирле бюджет үтәлеше турында) проекты басылып чыкканнан соң 15 календарь көннән дә иртәрәк үткәрелми.

5. Халык тыңлауларын билгеләү турында карар кабул иткән район Советы 5 кешедән торган оештыру комитетын төзи. Оештыру комитеты төзелгәннән соң 3 көннән дә соңга калмыйча уздырылган беренче утырышта үзенең составыннан рәисне, урынбасарны Һәм секретарьне сайлый. Оештыру комитеты утырышта аның әгъзаларының яртысыннан артыгы булганда карар кабул итәргә хокуклы.

Оештыру комитеты тыңлауларда катнашырга теләүчеләргә тыңлаулар үткәрелә торган бинага тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Халык тыңлауларын үткәрү көнендә оештыру комитеты халык тыңлауларында катнашучыларны теркәүне гамәлгә ашыра.

6. Халык тыңлауларында оештыру комитеты рәисе рәислек итә. Рәислек итүче халык тыңлауларын ача, халык тыңлауларының сорауларын, тыңлауларны үткәрү буенча тәкъдимнәрне игълан итә, үзе, секретарь һәм экспертлар белән таныштыра, тыңлаулар уздыру инициаторларын атый. Оештыру комитеты секретаре халык тыңлауларының беркетмәсен алып бара (1 кушымта).

7. Рәислек итүче фикер алышу үткәрелә торган сорау турында игълан итә һәм халык тыңлауларын үткәрү инициаторлары тарафыннан вәкаләтле затка, экспертларга, шулай ук чыгыш ясарга хокукы булган халык тыңлауларында катнашучыларга сүз бирә. Чыгышларның чиратлылыгы оештыру комитеты тарафыннан теркәлгән гаризалар бирү чираты белән билгеләнә.

8. Тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән экспертлар үз тәкъдимнәреннән кире кайтырга һәм (яки) башка халык тыңлауларында катнашучыларның тәкъдимнәренә кушылырга хокуклы.

Фикер алышу нәтиҗәләре буенча халык тыңлауларына чыгарылган мәсьәләне хәл итү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрнең бердәм исемлеге төзелә (тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кире алынган тәкъдимнәрдән тыш).

9. Тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр белән йомгаклау документы төзелгәннән соң, рәислек итүче әлеге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау вариантын тавышка куя. Халык тыңлауларында карарлар ачык тавыш бирү юлы белән тыңлауларда теркәлгән катнашучылар санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тыңлауларда катнашкан һәр кеше бер тавышка ия, ул җирле әһәмияттәге мәсьәләне тәкъдим иткән карар өчен, аңа каршы бирелә яисә тавыш бирүдән тыелып кала. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә. Беркетмәгә рәислек итүче һәм халык тыңлаулары секретаре имза куя.

10. Халык тыңлаулары беркетмәсе нигезендә тыңлаулар үткән көннән соң 3 эш көне эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә (2 кушымта) әзерләнә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) халык тыңлауларына чыгарылган сорау (сораулар);

2) халык тыңлауларын уздыру инициаторы;

3) халык тыңлауларын билгеләү турында хокукый актның датасы, номеры һәм исеме, шулай ук бастырып чыгару датасы;

4) халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны;

5) халык тыңлауларын үткәрүче оештыру комитеты;

6) халык тыңлауларында катнашучылар турында мәгълүмат, шул исәптән чыгыш ясарга хокуклылар хакында;

7) халык тыңлауларына чыгарылган мәсьәләне хәл итү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрнең бердәм исемлеге (тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кире алынган тәкъдимнәрдән тыш);

8) җирле билгеләнештәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты;

9) халык тыңлауларында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре.

11. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмәгә оештыру комитеты рәисе һәм секретаре тарафыннан кул куела һәм ул халык тыңлауларын үткәргән көннән соң 3 эш көнендә бастырып чыгарылырга тиеш.

12. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә халык тыңлауларына чыгарылган мәсьәләләр буенча карар кабул итү өчен җаваплы җирле үзидарә органы тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Карап тикшерү нәтиҗәләре мәҗбүри тәртиптә, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә карап тикшерелгәннән соң, 3 эш көнендә бастырып чыгару юлы белән муниципаль берәмлек халкына җиткерелә.

13. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш, тәкъдим итү характерына ия.

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җирле бюджет проекты буенча халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибенә 1 кушымта

# ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫ БЕРКЕТМӘСЕ

«____» _________ 20__ел №_____

Халык тыңлаулары ____________________________________________
инициативасы буенча билгеләнде
____________________________________________ № ____________ _____ ел
(муниципаль хокукый акт)
____________________________________________
(муниципаль хокукый акт исеме)
Бастырылган (халыкка җиткерелгән):____________________________
Үткәрү адресы: ________________________________________
Үткәрү вакыты: ______________________

Оештыру комитеты:________________________________

Катнаштылар: ________________________________

Рәислек итүче: ______________________________

Секретарь: __________________________________

Экспертлар: _________________________________

Халык тыңлауларында катнашучылар: (теркәлгән катнашучылар саны)______________

Халык тыңлауларында чыгыш ясаучы катнашучылар:________________________
____________________________________________
(Ф.И.А.и.)

Тыңланды:
1.____________________________________________
(Ф.И.А.и.)
2. ____________________________________________
(Ф.И.А.и.)
3. ____________________________________________
(Ф.И.А.и.)

Телдән һәм язма рәвештә кертелгән киңәшләр һәм тәкъдимнәр саны ______________________, шул исәптән:

| № | Киңәшләр һәм тәкъдимнәр | Гариза бирүче |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Халык тыңлауларында рәислек итүче ____________________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Халык тыңлаулары секретаре ____________________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.и.)

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җирле бюджет проекты буенча халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибенә 2 кушымта

# ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ

«___» _________ 20__ ел ___________

Халык тыңлаулары ______________________________________________
инициативасы буенча билгеләнде
______________________________________________ № ___________ _____ ел
(муниципаль хокукый акт)
______________________________________________
(муниципаль хокукый акт исеме)
Бастырылган (халыкка җиткерелгән):______________________________
Үткәрү адресы:______________________________________________
Үткәрү вакыты:_______________

Халык тыңлауларына чыгарылган сорау (сораулар)__________________

Халык тыңлауларын уздыру инициаторы __________________________

Халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны ________________

Халык тыңлауларын үткәргән оештыру комитеты____________________

Халык тыңлауларында катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясау хокукына ия булучылар турында мәгълүмат _________________________________________

Халык тыңлауларына чыгарылган җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итү буенча тәкъдимнәр һәм киңәшләрнең бердәм исемлеге:

| Фикер алышуга чыгарылган сораулар | | Экспертларның һәм катнашучыларның тәкъдимнәре һәм киңәшләре | | Тәкъдимнәр һәм киңәшләр (кертелде һәм хупланды) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| № | Сорауны формалаштыру яки проект исеме | № | Тәкъдим тексты | Экспертның (катнашучының) Ф.И.А.и. | |
| 1 | | 1.1 | | | |
| | | 1.2 | | | |
| 2 | | 2.1 | | | |
| | | 2.2 | | | |
| 3 | | 3.1<br>3.2 | | | |

Җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты:________________

Халык тыңлауларында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре:

хуплаучылар ____________________ (кеше)
каршылар ______________________ (кеше)
тыелып калучылар________________ (кеше)

Оештыру комитеты рәисе ______________________

Оештыру комитеты секретаре __________________